# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**12.11.2025 ел** **№5**

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Дәвек торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Дәвек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, һәм СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Дәвек т. п. зиратында койма кору (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
- Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Дәвек торак пунктындагы су җыю башнясы скважинасы өчен насос сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));
- Дәвек торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Пионерская урамы буенча юлга вак таш сатып алу һәм салу, кышкы чорда юлларны грейдерлау (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)).

3. Әлеге карарны Тауасты Байлар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районы сайтына http://menzelinsk/tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы З.С.Гәрәева